**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘТНӘ МУНИЦИАЛЬ РАЙОНЫ КҮЛЛЕ-КИМЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**СОВЕТ КУЛЛЕ-КИМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АТНИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422742 Республика Татарстан Атнинский район с. Кулле-Кими ул.Кирова 1А Тел. 3-53-40

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«2» ноябрь 2022 ел. № 4

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл жирлеге Ары торак пунктында гражданнарнын узара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар жыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә жирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында жирле узидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл жирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1. 2022 елнын 15 ноябрендә Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл жирлеге Ары торак пунктында узара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар жыены билгеләргә.

1.2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл жирлеге Ары торак пунктында узара салым керту мәсьәләсе буенча халык жыенын оештыручы-Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл жирлеге Башкарма комитеты;
- гражданнар жыенын үткәрү вакыты 15 ноябрь 2022 ел 18.00 сәг.тан 19.00 сәг.кадәр;
- уткәру урыны — Ары авылы, Колхоз урамы, 7 йорты;

1.3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл жирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2022 елның 2 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл жирлеге Башкарма комитетында гражданнар жыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Күлле-Киме авылы, Киров урамы, 1А йорты;
- сайлау хокукына ия булган Ары торак пунктында яшәучеләр исемлеген төзергә;
- гражданнар жыенына мәгълүмәти материаллар әзерләргә;
- Ары торак пункты халкына массакүләм мәгълүмәт чараларында һәм башка ысуллар белән гражданнар жыены турында хәбәр итәргә;

2. Гражданнар жыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез 2023 елда яшәү урыны буенча Әтнә муниципаль районы Кулле-Киме авыл җирлеге Ары торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидларыннан һәм мобилизацияләнгән

гражданнарның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- урамнарны кардан чистарту,
- урамнарны яктырту һәм яктырткычлар сатып алу
- зират коймасын ремонтлау өчен материаллар сатып алу
- Ары авылы юлларын ремонтлау вак таш алу һәм җәю, транспорт хезмәтләре күрсәтү

« РИЗА» «КАРШЫ»

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмәт рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмәт-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://atnya.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы, Ары авылы Колхоз ур.7 йортлардагы мәгълүмәт стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар, ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Күлле-Киме авыл җирлеге башлыгы: Х.Х.Гәрәев